СОВЕТ КУГУНУРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КУНЫР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
29 мая 2020 года

**КАРАР**
№ 148

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар (җәмәгать тыңлаулары) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлегендә яшәүчеләр белән җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышу, уңай тормыш шартларына кеше хокукларын саклау максатыннан, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлегенең халык алдында тыңлаулар турындагы нигезләмәне кабул итү турында " 2007 ел, 31 гыйнвар, 2 нче карары (28.12.2011 ел, №44) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru.

4. Үтәлешне контрольдә тотам.

Куныр башлыгы
авыл җирлеге башлыгы: Р.О.Егоров